Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Каракашлинская основная общеобразовательная школа»
Ютазинского муниципального района Республики Татарстан

РАССМОТРЕНО
Протокол заседания ШМО учителей
начальных классов
от 18.08.2020г. №1
Руководитель
________Нагимова И.С.
подпись

СОГЛАСОВАНО
Заместитель директора
по учебной работе
________Мугтасимова З.Н.
«18 »августа 2020г

УТВЕРЖДАЮ
директор МБОУ
« Каракашлинская ООШ»
________З.М.Шарафеева
Приказ № 71 от
«18» августа 2020г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

учебного предмета

## «ПО ЛИТЕРАТУРНОМУ ЧТЕНИЮ НА РОДНОМ ЯЗЫКЕ»

для начального общего образования
уровень образования

Классы: 1-4
Срок освоения программы: 4 года
Период освоения: 2019 -2020 – 2022-2023

Составители: учителя начальных классов, работающих по УМК «Школа России»

Мугтасимова З.Н., Ахметова Э.Ф., Мурасова Г.Р., Нагимова И.С..

ПРИНЯТА на заседании
педагогического совета
протокол № 1 от
«18» августа 2020 г.

2020 г.

## Аңлатма язуы

## Программа түбәндәге норматив документларга нигезләнеп язылды:

1. “Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль Закон, 2012. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы законы, 2013 ел.
2. ТР Ютазы муниципаль районының “Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль юджет белем бирү учреждениясенең 2020-2021 нче уку елына кабул ителгән укыту планы
3. **Дәреслек:** Г.Сафиуллина,М.Гарифуллина.,Ә Мөхәмәтҗанова.,Ф.Хәсәнова 3 кисәктә Казан, “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты

**Укыту программаларында шәхси, предмет һәм метапредмет нәтиҗәләре.**

**Башлангыч сыйныфны бетергәндә** укучы төп мәктәп программасын үзләштерергә әзер була, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә шактый белем туплый.
- текст өстендә эшли ала: кирәкле информацияне эзләп таба, урынлы куллана белә: дәреслектә иркен ориентлаша, берничә чыганактан мәгълүмат туплый, сүзлекләр белән эш итә, вакытлы матбугатка күзәтү ясый һәм мәктәп китапханәсе фондыннан файдалана;
- әдәбиятның сүз сәнгате булуына инана, мәгълүматлар туплый;
- әдәби әсәрләр аша әхлак нормаларының үтәлешенә ирешә;
- әдәби әсәрләрне анализлый, аларга дөрес бәя бирә белә.

“***әдәби уку”курсы программасы 1 нче сыйныфны тәмамлаганда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне бурыч итеп куя.***
“***Сөйләм төрләре, укучы эшчәнлеге”бүлегендә:***
Укучылар өйрәнәләр:
- кычкырып укыганда индивидуаль темп белән йөгерек, иҗекләрне өзмичә сүзләп укырга;
- ишеткән, яисә сыйныфта укыган кыска әсәрләрнең эчтәлеген аңларга, төп мәгънәләрен әйтә белергә;
- текстның маркирланган өлешен эчтән укып, эчтәлеген аңларга;
- төрле авторларның 3-4 әсәрләрен ятлап укырга.

**Укучы мөстәкыйль һәм парлы эшчәнлек барышында өйрәнергә мөмкинлек ала:**
- дәреслекнең “Эчтәлек”битендә кирәкле әсәрләрне таба белергә;
- укылган әсәр буенча сораулар төзи, эчтәлеген сөйли һәм тексттан файдаланып сорауларга җавап бирә белергә.

“***Әдәби пропедевтика”бүлегендә***
**укучылар өйрәнәләр:**

• проза әсәрләрен шигъри әсәрләрдән аера белергә;
• фольклорның кече жанрларын (табышмак, санамыш, тизәйткеч, әйтешләр, уйдырмалар) аера белергә;
• әдәби текстта кабатлаулар, җөмлә төрләрен, тыныш билгеләрен, ритм һәм рифмаларны таба белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала**:
• әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен аерырга (чылбыр әкиятләрне аптыраткыч әкиятләрдән);
• кече фольклор әсәрләрендә төрлелекне тоемлый белергә ( хикәя - әкият, бишек җырлары - әйтешләр).

“***Укучыларның иҗади эшчәнлеге” бүлегендә***

**Укучылар өйрәнәләр:**
• текстны укыганда дөрес интонация, уку темпын сайлап, паузалар белән укый белергә;
• әдәби әсәрләрне укыганда текст кырындагы маркировкага нигезләнеп (төсле полоскалар) рольләргә бүленеп, чылбыр рәвешендә укый белергә;
• әсәргә ясалган иллюстрациягә туры килгән өлешне тексттан таба белергә.

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:**
• кече фольклор жанры әсәрләрен практик өйрәнергә **(**табышмак, санамыш, тизәйткеч, әйтешләр, уйдырмалар)**,** аларны мимика, хәрәкәтләр белән бирә белергә;
• “Музей йорты” бүлегендә (Рәссам Фәридә Ризаева күргәзмәсе) иллюстрацияләрне табып, дәреслекнең кайсы текстына туры килүен ачыкларга, текстның иллюстрация белән ни дәрәҗәдә туры килүен ачыкларга.

**1 нче сыйныфны тәмамлаганда универсаль укыту гамәлләре формалаштыруда көтелгән нәтиҗәләр**

**Гомуми танып белү эшчәнлеге өлкәсендә**

**укучылар өйрәнәләр:**
• Дәреслектә җиңел ориентлашырга, дәреслекнең шартлы билгеләрен төгәл белергә, тексттагы аерым өлешләрне, юлларны, сүзләрне табарга, дәреслек ахырында бирелгән бүлек белән эшли, кирәкле иллюстрацияне таба белергә;
• дәрестә кимендә ике чыганак (дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәре яки дәреслек һәм хрестоматия**)** белән эшли белергә;

**Коммуникатив эшчәнлек өлкәсендә:**

**укучылар өйрәнәләр:**
• партадашы белән эшли, эшләрне үзенә һәм иптәшенә куша белә, үзенә тапшырылган эшне башкара, үзбәя бирә, иптәше эшләгән эшнең нәтиҗәсе белән кызыксына белергә;
• чылбыр рәвешендә укырга (текст кырындагы шартлы билгеләрне куллана);
• әсәрләрне чагыштыра, нәтиҗә ясарга;

**Уку эшчәнлеген бәяләү, үзбәя өлкәсендә**

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:**
• сорауларга җавапны төрлечә биреп булуын аңлый;
• текст өстендә эшләү аша җавапларны таба, дөрес җавапны билгели, дәлилли ала**.**

*“Әдәби уку”курсы программасы 2 нче сыйныфны тәмамлаганда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне планлаштырыла.*

“***Сөйләм төрләре, укучы эшчәнлеге”бүлегендә:***

**Укучылар өйрәнәләр:**

• сүзләрне укыганда төгәл, дөрес әйтеп укырга, уку тизлеген арттыра барырга;
• текст белән беренчел танышканда эчтән укырга, терәк сүзләрне эзләп табып, кирәкле өзек белән танышырга;
• үз фикерен белдерү өчен кыска монологлар төзергә, укытучы сорауларына тулы җавап бирергә;
• укытучыны, сыйныфташларын тыңларга, сорауларга җавап биргәндә иптәшләрен кабатламаска, үз фикерләрен төгәл әйтә белергә;
• 2-3 татар, рус классикларының исемен әйтергә;
• дәреслектә танышкан 2-3 хәзерге заман язучылары яки шагыйрьләрен , алар язган әсәрләрне әйтергә, эчтәлеген сөйләргә;
• үзенең яраткан авторы турында, аның әсәрләре турында сөйли белергә;
• бирелгән текстның темасын, төп мәгънәсен ачыкларга (укытучы ярдәме белән);
• аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен Аңлатмалы сүзлектән ачыкларга;
• әсәр геройларына характеристика бирергә.

**Мөстәкыйль, парлы, төркемнәрдә эшләгәндә укучылар эшләргә өйрәнергә мөмкинлек ала:**

• укытучы укыган текстны аңлый, үз фикерен белдерә;
• “Серле ачкыч” мәктәп клубына хат яза;
• укыган әсәргә үз фикерен белдерә ала;
• төрле авторларның 6-8 шигырен яттан укый ала;
• китапханәдән китаплар сайлаганда кирәкле әсәрне “Эчтәлек ” битеннән эзли belә;
• теманы өйрәнгәндә охшаш текстларны, бер үк автор әсәрләрен хрестоматиядән эзләп таба ала;
• укылган тексттан өземтәләр китереп сорауларга җавап бирә.

**“Әдәби пропедевтика” бүлеге**

**Укучылар өйрәнәләр:**

• тылсымлы әкиятләрне хайваннар турындагы әкиятләрдән аерырга;
• тылсымлы әкиятләрнең үзенчәлеген ачыкларга;
• әкият һәм хикәяне аерырга;
• әсәрдә сурәтләү чараларын табарга (чагыштырулар, капма-каршылык, кабатлаулар, җанландыру һ.б);

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:**

• Автор әсәрләрендә фольклор элементларының чагылышын , әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен ачыклый;
• әдәби әсәрләр һәм фолҗклор арасындагы чикнең сыгылмалылыгын билгели (хикәядә әкият элементлары , тылсымлы әкияттә-хайваннар турындагы әкият элементлары чагылышы);
• табигатьне шагыйрь күзлегеннән карап танып белә.

“***Укучыларның иҗади эшчәнлеге” бүлегендә***

**Укучылар өйрәнәләр**:
• укылганның эчтәлеген аңларга, интонация, уку темпын сайларга, паузалар белән укырга;
• әдәби текстны дәреслек битендәге маркировка белән дөрес итеп рольләргә бүлеп, чылбыр рәвешендә укырга;
• программада каралган текстларны аңлап укырга һәм эчтәлеген сөйләргә.
**Мөстәкыйль, парлы, төркемнәрдә эшләгәндә укучылар өйрәнергә мөмкинлек ала:**
• шигъри һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерә;
• дәреслектә бирелгән иллюстрацияләрне, “Музей йорты”ндагы картиналарны карап, әдәби текстлар белән чагыштырып, уртак һәмт аермалы якларын таба;
• әдәби һәм сәнгать әсәрләре турында телдән сөйләм төзи.

**2 нче сыйныфны тәмамлаганда универсаль укыту гамәлләре формалаштыруда көтелгән нәтиҗәләр**

**Гомуми танып белү эшчәнлеге өлкәсендә**
**укучылар өйрәнәләр**
• сүзлекләр белән эш итәргә, кирәкле сүзне эзләп табарга, мәгънәсен ачыкларга;
• дәреслектә ориентлашырга, текстны эзләгәндә “Эчтәлек” бите белән эшли белергә;
• берничә төрле информация чыганаклары белән эшли белергә (дәреслек, мөстәкыйль эш дәфтәре, хрестоматия, сүзлекләр, иллюстрацияләр)
**Коммуникатив уку гамәлләре өлкәсендә**
**укучылар өйрәнәләр:**
• партадашы белән эшли белергә, һәркемгә эш бүлешергә, үз эшчәнлеген, иптәшенең башкарган эшен тикшерергә**;**
• чылбыр рәвешендә эш итәргә;
• ике төрле караш булганда бер фикергә килә белергә;
• әсәр геройларының фикерләрен таба белергә.
**Контроль һәм үзконтроль өлкәсендә**
**Укучылар өйрәнергә мөмкинлек ала;**
• әйтелгән фикерне раслау өчен, тексттан өземтәләр китерергә;
• төрле фикерләрнең нәрсәгә таянуын ачыкларга.
“***Әдәби уку”курсы программасы 3 нче сыйныфны тәмамлаганда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне планлаштырыла.***
“***Сөйләм төрләре, укучы эшчәнлеге”бүлегендә:***
**Укучылар өйрәнәләр:**
• сүзләрне укыганда төгәл, дөрес әйтеп укырга, уку тизлеген арттыра барырга;
• текст белән беренчел танышканда эчтән укырга, терәк сүзләрне эзләп табып, кирәкле өзек белән танышырга, өзекне сайлап укырга;
• “Серле ачкыч” мәктәп клубы белән эшчәнлекне дәвам итәргә, алынган хатларны укып дөрес бәяләргә;
• укытучыны, сыйныфташларын тыңларга, сорауларга җавап биргәндә иптәшләрен кабатламаска, үз фикерләрен төгәл әйтә белергә;
• төрле авторларның 6-8 әсәрен яки алардан өзекне яттан сөйләргә;

• дәреслектә танышкан әсәрләрнең кайсы язучыныкы яки шагыйрьнеке икәнен, алар язган әсәрләрне әйтергә, эчтәлеген сөйләргә;
• үзе яраткан автор, аның әсәрләре турында сөйли белергә;
• бирелгән текстның темасын, төп мәгънәсен ачыкларга, авторның үз героена мөнәсәбәтен ачыкларга;
• аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен Аңлатмалы сүзлектән ачыкларга;
• әсәр геройларына характеристика бирергә;.

**Мөстәкыйль, парлы, төркемнәрдә эшләгәндә, коллектив эш вакытында укучылар эшләргә өйрәнергә мөмкинлек ала**

• мөстәкыйль рәвештә тематик, жанрлар буенча җыентыклар төзи;
• уку өчен мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлый, китап элементлары буенча эчтәлекне ачыклый;
• сайлап алган китапларын мөстәкыйль укый;
• сүзлекләр белән мөстәкыйль эш итә.

“**Әдәби пропедевтика” бүлеге**

**Укучылар өйрәнәләр:**

• тылсымлы, хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне , тормыш көнкүреш әкиятләрен аерырга;
• тормыш көнкүреш һәм тылсымлы әкиятләрнең үзенчәлеген ачыкларга;
• әкият һәм хикәяне аерырга;
• әсәрдә сурәтләү чараларын табарга (чагыштырулар, капма-каршылык, кабатлаулар, җанландыру һ.б);

**Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:**

• хайваннар турындагы әкиятләрнең кайчан килеп чыгышы ;турында фикерли ала;
• .төрле халыклар әкиятләрендә йөремсәк сюжет булуын ачыклый

“***Укучыларның иҗади эшчәнлеге” бүлегендә***

**Укучылар өйрәнәләр:**

• укылган әсәрнең эчтәлеген аңларга, интонация, уку темпын сайларга, паузалар белән укырга;
• әдәби текстны дәреслек битендәге маркировка белән дөрес итеп рольләргә бүлеп, чылбыр рәвешендә укырга;
• әсәрләр буенча инсценировкалар әзерләгәндә катнашырга.

**Мөстәкыйль, парлы, төркемнәрдә эшләгәндә укучылар эшләргә өйрәнергә мөмкинлек ала:**

• шигъри һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерә;
• дәреслектә бирелгән иллюстрацияләрне, “Музей йорты”ндагы картиналарны карап, әдәби текстлар белән чагыштырып, уртак һәмт аермалы якларын таба;
• әдәби һәм сәнгать әсәрләре турында телдән сөйләм төзи.

**3 нче сыйныфны тәмамлаганда универсаль укыту гамәлләре формалаштыруда көтелгән нәтиҗәләр**

**Гомуми танып белү эшчәнлеге өлкәсендә**

**укучылар өйрәнәләр**

• сүзлекләр белән иркен эш итәргә, кирәкле сүзне эзләп табарга, мәгънәсен ачыкларга;

• дәреслектә ориентлашырга, шартлы билгеләрне яхшы белергә, текстны эзләгәндә “Эчтәлек” бите белән эшли белергә, төс белән аерылган текст фрагментларын табарга, махсус билгеләнгән информацияләр белән эш итәргә;
• текст өстендә эшләргә, тема һәм төп мәгънәне ачыкларга,
• берничә төрле информация чыганаклары белән эшли белергә (дәреслек, мөстәкыйль эш дәфтәре һәм хрестоматия, дәреслек һәм сүзлекләр, иллюстрацияләр һәм картиналар, комплектта булган башка дәреслекләр (әйләнә-тирә дөнья), китапханәдән алынган китаплар, Интернет материаллары.

**Укучылар өйрәнергә мөмкинлек ала:**

• җыентыкларның төзелеш алгоритмын өйрәнә: монографик, тематик (терминнар кулланылмый)

**Коммуникатив уку гамәлләре өлкәсендә**

**укучылар өйрәнәләр:**

• партадашы белән кечкенә һәм зур төркемнәрдә эшли белергә, һәркемгә эш бүлешергә, үз эшчәнлеген, иптәшенең башкарган эшен тикшерергә;
• ике төрле караш булганда бер фикергә килә белергә;
• әсәр геройларының фикерләрен таба белергә, үз фикерен әйтергә һәм башка фикерләр белән уртак нәтиҗәгә килергә.

**Контроль һәм үзконтроль өлкәсендә**

**Укучылар өйрәнергә мөмкинлек ала;**

• әйтелгән фикерне раслау өчен, тексттан өземтәләр китерергә, соңгы нәтиҗәнең дөреслегенә инанырга.;

“***Әдәби уку”курсы программасы 4 нче сыйныфны тәмамлаганда түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү планлаштырыла..***

“***Сөйләм төрләре, укучы эшчәнлеге”бүлегендә:***

Укучылар өйрәнәләр:

• укуның төрле формаларыннан файдаланырга: эчтән, кычкырып, сайлап, рольләргә бүлеп укырга;
• текст белән беренчел танышканда эчтән укырга, терәк сүзләрне эзләп табып, кирәкле өзек белән танышырга, өзекне сайлап укырга, текстның темасын һәм төп мәгънәсен ачыкларга, әсәрне мәгънәви кисәкләргә бүлә, план төзи, әсәрнең эчтәлеген кыскача һәм тулысынча сөйли белергә;
• “Серле ачкыч” мәктәп клубы белән эшчәнлекне дәвам итәргә, алынган хатларны укып дөрес бәяләргә һәм җавап хаты язарга;
• укытучыны, сыйныфташларын тыңларга, сорауларга җавап биргәндә иптәшләрен кабатламаска, үз фикерләрен төгәл әйтә белергә;
• төрле авторларның әсәрләрен яки алардан өзекне яттан сөйләргә, укытучы яки иптәшләренең төзәтүләрен тыныч кабул итәргә, ;
• дәреслектә танышкан әсәрләрнең кайсы язучыныкы яки шагыйрьнеке икәнен, алар язган әсәрләрне әйтергә, эчтәлеген сөйләргә;
• 2-3 балалар газетасы яки журналы турында сөйли белергә;
• бирелгән текстның темасын, төп мәгънәсен ачыкларга, авторның үз героена мөнәсәбәтен аңлатырга;
• тематик, монографик һәм төрле жанрлар буенча җыентыклар төзергә, әсәргә аннотация язарга;
• әсәр геройларына характеристика бирергә;.
• төрле чыганаклардан мәгълүматлар тупларга;

• китапханәдә укытучы тәкъдим иткән китапны эзләп табарга.

“**Әдәби пропедевтика” бүлеге**
**Укучылар өйрәнәләр:**
• халык иҗаты һәм автор әсәрләре турында тулы кузаллау булдырыла, халык иҗаты әсәрләрен автор әсәрләреннән аера белергә;
• әсәрдә сурәтләү чараларын табарга (чагыштырулар, капма-каршылык, кабатлаулар, җанландыру һ.б);
**Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:**
• мифлар, төрле халыклар әкиятләрендә аларның бирелешен өйрәнә;
• .төрле халыклар әкиятләрендә географик һәм тарихи атамаларның бирелешен ачыклый;
• язучыларның иҗат биографияләре белән таныша;
“***Укучыларның иҗади эшчәнлеге” бүлегендә***
**Укучылар өйрәнәләр:**
• укылган әсәрнең эчтәлеген аңларга, интонация, уку темпын сайларга, паузалар белән укырга;
• әдәби текстны дәреслек битендәге маркировка белән дөрес итеп рольләргә бүлеп, чылбыр рәвешендә укырга;
• әсәрләр буенча инсценировкалар әзерләгәндә катнашырга, үзе дә иҗат итәргә(хикәя, шигырь, мәсәл, мәкалә һ.б.).
**Мөстәкыйль, парлы, төркемнәрдә эшләгәндә укучылар эшләргә өйрәнергә мөмкинлек ала:**
• шигъри һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерә;
• дәреслектә бирелгән әдәби, сынлы сәнгать, музыкаль әсәрләр, иллюстрацияләр турында иптәшләре белән сөйләм төзи.
• әдәби һәм сәнгать әсәрләре турында телдән һәм язма сөйләм төзи.

**4 нче сыйныфны тәмамлаганда универсаль укыту гамәлләре формалаштыруда көтелгән нәтиҗәләр**

**Гомуми танып белү эшчәнлеге өлкәсендә**
**укучылар өйрәнәләр**
• дәреслектә бирелгә текст, сүзлекләр белән иркен эш итәргә, кирәкле сүзне эзләп табарга, мәгънәсен ачыкларга;
• дәреслектә ориентлашырга, шартлы билгеләрне яхшы белергә, текстны эзләгәндә “Эчтәлек” бите белән эшли белергә, төс белән аерылган текст фрагментларын табарга, махсус билгеләнгән информацияләр белән эш итәргә;
• текст өстендә эшләргә, тема һәм төп мәгънәне ачыкларга, вакытлы матбугат белән эшләргә,
• берничә төрле информация чыганаклары белән эшли белергә (дәреслек, мөстәкыйль эш дәфтәре һәм хрестоматия, дәреслек һәмсүзлекләр, иллюстрацияләр һәм картиналар, комплектта булган башка дәреслекләр (әйләнә-тирә дөнья), китапханәдән алынган китаплар, Интернет материаллары.
**Коммуникатив уку гамәлләре өлкәсендә**
**укучылар өйрәнәләр:**
• партадашы белән кечкенә һәм зур төркемнәрдә эшли белергә, инсценировкалар вакытында төрле рольләрне башкара белергә;

• ике төрле караш булганда бер фикергә килә белергә,үз фикерен әсәрдән өзекләр белән ныгытырга, иптәшләре җавапларын игътибар белән тыңларга;
• әсәр геройларының фикерләрен таба белергә, үз фикерен әйтергә һәм башка фикерләр белән уртак нәтиҗәгә килергә.

**Контроль һәм үзконтроль өлкәсендә**

**укучылар өйрәнергә мөмкинлек ала;**

• әйтелгән фикерне раслау өчен, тексттан өземтәләр китерергә, соңгы нәтиҗәнең дөреслегенә инанырга, җавапларга үзбәя бирә белергә һәм иптәшләренең җавапларын бәяләргә.;

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны.**

Әдәби уку филология фәннәре өлкәсенә керә.

I сыйныф – 1 сәгать – 33 сәгать;

II сыйныф – 1 сәгать – 34 сәгать;

III сыйныф – 1 сәгать – 34 сәгать;

IV сыйныф – 1 сәгать – 34 сәгать.

Барлыгы 135 сәгать.

1 сыйныф

| № | Төп темалар | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Телдән әзерлек чоры. | 2 сәгать |
| 2 | Әлифба чоры. | 23 сәгать |
| 3 | Әлифбадан соңгы чор. Әдәби уку. | 8 сәгать |
| | Барлыгы. | 33 сәгать |

**Уку предметының эчтәлеге.**

***Әзерлек чоры. (2 сәг)***

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчедән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү.

Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.

Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу

***Әлифба чоры. (23 сәг)***

Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.

Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.

Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.

Парсыз сонор тартык авазлар

[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр.

Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре (а, у, о, ы) белән (ма, му), нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре (ә, и, ө, ү, э) белән белдерү. Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү.

Чагыштыру өчен бирелгән сүзләрдәге (мал-мәл) авазларның аермалы билгеләренең мәгънә функциясенә ия булуын билгеләү.

Сонор авазларны белдерүче басма баш һәм юл хәрефләрнең формаларын үзләштерү. Ябык иҗекләрне (ай) һәм калын һәм нечкә яңгырашлы кушылмаларны (ма, мә, му, мү һ.б.), шулай ук парсыз тартык авазлар уртада һәм ахырда булган сүзләрне (май, малай) уку. Сүзләрне иҗекләп уку белән чагыштырып, орфоэпик уку һәм әйтү алымы.

Сүз башында һәм сүз уртасында |й] авазы

Я, е, ю хәрефләренең ике авазга [йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү] билге булып килүләре: яра, ял, юл, куян, баян.

Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү.

Я, е, ю хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек яңгырау, саңгырау ([д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ] һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән бар-бар, бар-пар һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү.

Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре (бар-пар).

Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.

Башлангыч сүзне һәм сүзнең авазын алмаштыру яки аваз өстәү юлы белән ясалган яңа сүзләрне (бур-бура-буран), шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган (ана) сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.

Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру.

Аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ тан соң [й] авазы

Язуда аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә [й] авазының язуда бирелешен (ь+е, я, ю; ъ+е, ю, я) аңлату. (Я, е, ю хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә (алъяпкыч) ъ билгесе, алдагы иҗек нечкә сүзләргә (дөнья) ь билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән [й] авазлы сүзләрнең аваз анализы. [Й] авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку. аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку.

Ь, ъ билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

(Бу билгеләрнең [гъ], [къ] авазларының калынлыгын белдерү өчен дә кулланылуын аңлату (игътибар, тәкъдим). Калын [гъ] һәм [къ] авазлары булган сүзләрнең калынлыгын белдерү өчен язуда калын сузык аваз хәрефләре куланылуын, әйткәндә, иҗек нечкәлеген белдерү өчен, ахырдан ь билгесе куелуын ассызыклан үтәргә кирәк. Мәсәлән мәкаль сүзендә [къ] калын кече тел тартыгы, аның калынлыгын белдерү өчен к дан соң а язабыз, укыганда [мәкъәл] дип укыйбыз, икенче иҗекне нечкә итеп уку өчен сүз ахырына ь билгесе куябыз.)

Парсыз тарлык авазлар.

Парсыз [х, һ, щ, ц] тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

***Әлифбадан соңгы чор (8 сәг)***

Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу.Текстның 1) башлам (вакыйга нәрсәдән башалана). 2) төп өлеш (катнашучы-геройлар белән нәрсә була), 3) йомгаклауга (нәрсә ничек тәгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текста сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү.

**Әдәби укуга 2 нче сыйныфта укыту планында атнага 1 сәгать вакыт бирелгән, программа 34 сәгатькә исәпләп төзелде.**

| № п/п | Бүлек исеме | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Белдекле Керпедә кунакта | 9 |
| 2 | Белмәмештә кунакта | 3 |
| 3 | Укымышлы Ябалак янында | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 4 | Аю өнендә | 3 |
| 5 | Күрү ноктасы | 10 |
| 6 | Балалар газета-журналлары | 1 |
| 7 | Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья | 4 |
| 8 | Кызык һәм көлкеле хәлләр | 2 |
| Барлыгы | | 34 |

**Программа эчтәлеге**

1. Белдекле Керпедә кунакта (9 сәгать)
Хайваннар турында әкиятләр. Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.
Тылсымлы әкиятләр. Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар (эченнән гаскәр чыга торган таяк, төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек,җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ.б.), герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак,көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар (җәнлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, шулай ук убырлы карчык һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелүе).
Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру).
2. Белмәмештә кунакта(3 сәгать)
Шигъри формада язылган әсәрләр(Р. Вәлиева, Ф. Яруллин, Җ. Дәрзаман ,Йолдыз). Йолдыз “Белмим”, Р.Вәлиева “Замана баласы”, Ф.Яруллин “Эшнең аның берние юк”, Җ.Дәрзаман “Солдат булдым”.
Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).
3. Укымышлы Ябалак янында (2 сәгать)
Г.Тукай ,Н.АхуноваА., Р Вәлиева,Р.Файзуллин, Э. Шәрифуллина әсәрләре; Г.Тукай ”Буран”; кыска шигырьләр;Н.Ахунова “Хоккулар”;Э.Шәрифуллина “Алтын балык”
Жанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.

4. Аю өнендә (3 сәгать)
Л. Лерон,И.Туктар,Р.Миңнуллин әсәрләрен уку.
Л.Лерон “И ямьле дә соң дөнья!”
И.Туктар “Урман букеты”.
Р.Миңнуллин “Чыршы әйләнәсендә”.
Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).
5. Күрү ноктасы (10 сәгать)
Р.Харис,Ш.Галиев,Ф.Садриев,Р.Миңнуллин, Р.Сарби,Г.Юнысова,Г.Гыйльманов,Н.Арсланов, М.Әгъләмов,М.Шабаев,Н.Мадьяров,З.Минһаҗева,Г.Шаһи,Ф.Зыятдинов,Р.Файзуллин, Г.Тукай,Р.Хафизова,Ж.Дәрзаман,Б.Рәхмәт,Р.Корбан,ЛЛерон,Ә.Моталлапов, Г.Афзал,Р.Валиева әсәрләрен уку.
6. Балалар газета-журналлары(1сәгать)
Газета-журналларның ни өчен вакытлы матбугат дип аталуын,яңалык белән гайбәт арасындагы аерманы аера белү. Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация,тон, темп саклап кычкырып уку). Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау.Татар телендә чыга торган балалар журналларын белү. журналларда һәм газеталарда ориентлаша белү.
7. Шагыйрь өчен табигать-серле һәм җанлы дөнья(4 сәгать)
Г.Морат, Г.Хәсәнов, Ә.Еники, Р.Мингалим, Йолдыз, Ф.Сафин, М.Фәйзуллина, Р.Газизов, С.Урайский, Л.Лерон, М.Галиев,М.Шабаев, Э.Шәрифуллина, Г.Мөхәммәтшин,Р.Вәлиева, Р.Корбан әсәрләре.
8. Кызык һәм көлкеле хәлләр(2 сәгать)
Л.Лерон, М.Шабаев, Э.Шәрифуллина әсәрләре.

**Әдәби укуга 3 нче сыйныфта укыту планында атнага 1 сәгать вакыт бирелгән, программа 34 сәгатькә исәпләп төзелде.**

| **Бүлекнең исеме** | **Эчтәлек** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|---|
| Дәреслекнең беренче кисәге. Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз | Табигатьнеӊ гүзәллеген әдәби һәм сәнгать әсәрләре аша аңлату. Балаларны табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтеп барырга, күргәннәреӊ белән уртаклашырга өйрәтү. Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгының шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуына инандыру. Шигырьләрдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, | **7** |

| | | |
|---|---|---|
| | тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү).<br>Б. Рәхмәт “Иң күңелле чак”, Р. Хисмәтуллин «Июль аланы», Р. Вәлиева “Җәй һәм бала”, М. Галиев «Җиләктән кайтканда», М. Мирза “Көздә бермәл”, “Көз”, “Болыт”, Б. Рәхимова «Шук болытлар, батыр җил, якты кояш», М. Гафури “Болын”, Н. Дәүли «Бала болыт», . Р. Корбан “Көз нигә моңая”, Р. Вәлиева “Яңгыр, яу!”, “Китмә әле, бераз тор”, Йолдыз “Салават күпере”, М. Әлимбаев “Салават күпере”, Л. Лерон «Яңгырның ял көне», М. Җәлил “Яңгыр”, Р. Мингалим «Август каеннары», Ш. Маннур “Көзге урманда”, З. Туфайлова «Яфрак ява», Х. Әюпов «Әбиләр чуагы», К. Тәхау “Көзге урман”, Р. Әхмәтҗан “Соңгы яфрак”, М. Мазунов «Карап торам», Г. Хәсәнов «Кыр казы», Г. Бәширов «Ана каз белән ата каз һәм аларның унике бәбкәсе», Н. Гыйматдинова «Казлар», Г. Остер «Серне ачты», В. Хәйруллина “Тәрбияче попугай”, Н. Сладков “Кузалдавычлар”, Р. Әхмәт “Сыкы”, Н. Сладков “Кем остарак”, Р. Корбан “Мәктәпкә озату бәйрәме”, Г. Паушкин “Кыш”, Г. Рәхим “Безнең тауда”, Н. Әхмәдиев “Чишмәгә суга барам”, К. Кәримов “Кышкы мәтрүшкәләр”, Н. Гыйматдинова Сарбай”.<br>**Эш формалары**: практик-уен, экскурсия, иҗади эш, яттан сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Кеше һәм табигать бергәлеген, дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзалларга,әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы —шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инанырга. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитетларны аерырга, автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлыкны,чагыштыру, контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белергә, аңлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерергә(темп,тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү,түбәнәйтү)<br>**Милли төбәк компоненты:** Татар язучылары иҗаты белән танышу. | |
| Чагыштырулар серенә төшенәбез. | Әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.<br>Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә | **3** |

| | | |
|---|---|---|
| | осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында күзаллау.<br>Әфган халык әкияте: “ Иң яхшы дару”, “Табышны ничек бүләргә?”, “Кабартма”; Уйгур халык әкияте: “Тылсымлы китмән”; Инглиз халык әкияте: “Көрән төстәге пингвин баласы”; Монгол халык әкияте: “Әтәч таңда нигә кычкыра?”; Манси халык әкияте: “Куянның колагы нигә озын?”; Кабарда халык әкияте: “Җәнлекләр патшасы”; Венгр халык әкияте: “Комсызлык бәласы”; Африка негрлары әкияте: “Сырны ничек бүлгәннәр?”; Эстон халык әкияте: “Куянның ирене нигә ярык?”; Эвенк халык әкияте: “Әтәч нигә кычкыра?”; Казакъ халык әкияте: “Юмарт дөя”; Нугай халык әкияте: “Карт һәм су анасы”; Норвегия халык әкияте: “Кабартма”; Алман халык әкияте: “Сандугач белән Аю”; Каракалпак халык әкияте: “Җәй белән Кыш нигә күрешми?”; Латыш халык әкияте: “Шайтанга ничә яшь?”; Литва халык әкияте: “Итагатьле мәче”, Л. Лерон “Әкияти башламнар”, Йолдыз “Охшашлык”, Э. Шәрифуллина “Әкият кайда?”<br>**Эш формалары:** практик-уен, иҗади эш, эчтәлек сөйләү, төркемдә һәм парларда.<br>**Укучыларның белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләр:**<br>Дәреслекнең төзелешен белергә,әкиятләрнең автор һәм халык әкиятләренә бүленешен аерырга,эчтәлек битендә ориентлаша алырга, халык һәм автор әкиятләрен аерырга, иллюстрацияләр аша әкиятләрне танырга,әкиятләрне мәгънәви кисәкләргә бүлә белергә,кыен хәлләргә калганда авырлыкларны җиңә белергә, әкиятләрнең үзенчәлекләрен мөстәкыйль рәвештә күрә белергә, укыган әкиятләр арасыннан тылсымлыларын аера белергә, җәнлекләр турындагы татар халык әкиятләрен башка халык әкиятләре белән чагыштырып үзенчәлекле якларын таба белергә<br>**Милли төбәк компоненты:** Төрле халык авыз иҗаты белән танышу. | |
| Кешеләрнең хыялларын аңларга тырышабыз | Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы – тыңлаучыга табигый көчләрнең серен , әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү. Уйдырмаларның максаты – тыңлаучыларны дөньяда булмаган,уйлап чыгарылган хәлләр белән шаккатыру.<br>Л. Лерон “Хыял”, Йолдыз “Антенналы бәрәңге”, Л. Лерон “Хыялый Акбай”, Ә. Габиди “Тере антенналар”, Л. Лерон “Мәче малае Шукбай”, “Шукбай балык тота”, “Хат”, Ф. Мөслимова “Хыялый”, З. Гомәрова “Хыялларым”, Б. Рәхмәт “Ничек өйрәнергә”, Р. Фәйзуллин “Тугайда”, А. Әхмәтгалиева “Болытта җиләк үсә”, Ф. Садриев “ Юкка көттеләр”, А. Гыйләҗев “Суык”, А. Аланазаров “Дустымны эзлим2, В. Хәйруллин | **3** |

| | | |
|---|---|---|
